**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 26 маендагы 1808 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 8283 номерлы карары белән расланган М-8А микрорайоны территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 8283 номерлы карары белән расланган М-8А микрорайоны территориясен планлаштыру проектына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 29 декабрендәге 4732 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карарның кушымтасы нигезендә территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, гомуми кулланудагы территорияләрнең билгеләнә торган кызыл линияләренең борылу нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) тыш, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында

(www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 26 маендагы
1808 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 8283 номерлы карары белән расланган М-8А микрорайоны территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген әлеге үзгәрешләрнең кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә.

___________